РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ШЕМОРДАНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422050, Республика Татарстан, Сабинский район,
с. Шемордан, ул. Лермонтова, 2
тел. (84362) 3-21-44

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ШЭМЭРДЭН АВЫЛ
ЖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

422050, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Шэмэрдэн авылы Леронтов урамы, 2 йорт
тел. (84362) 3-21-44

e-mail: Shmd.Sab@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

14.12.2018 — № 62-п

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы
Шәмәрдән авыл җирлегендә урнашкан күпфатирлы
йортларда гомуми милекне кичектергесез капитал
төзекләндерү зарурлыгы килеп чыккан очракта җирле
бюджет хисабына кире кайтару һәм (яки) кире кайтармау
нигезендә өстәмә ярдәм күрсәтү очраклары исемлеген
һәм тәртибен раслау турында

“ Россия Федерациясендә Торак кодексына үзгәрешләр кертү турында” 20.12.2017 елгы №399-ФЗ Федерал законга һәм “Россия федерациясендә торак фондын приватизацияләү турында” 04.07.1991 елгы №1541-1 Россия федерациясе законының 16 статьясына туры китереп, Саба районы прокуратурасының тәкдиме белән, Шәмәрдән авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлегендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми милекне кичектергесез капитал төзекләндерү зарурлыгы килеп чыккан очракта җирле бюджет хисабына кире кайтару һәм (яки) кире кайтармау нигезендә өстәмә ярдәм күрсәтү очраклары исемлеген һәм тәртибен расларга. (теркәлә)

2. Әлеге карарны “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлегенең рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/shemordan адресы буенча бастырырга;

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Шәмәрдән авыл җирлеге башлыгы: А.Н.Гараев

Татарстан Республикасы Саба
муниципаль районы Шәмәрдән авыл
җирлеге башкарма комитетының
14.12.2018 ел 62-п номерлы карары
белән расланган

**Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлегендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми милекне кичектергесез капитал төзекләндерү зарурлыгы килеп чыккан очракта җирле бюдџет хисабына кире кайтару һәм (яки) кире кайтармау нигезендә өстәмә ярдәм күрсәтү очраклары исемлеген һәм тәртибе**

1. Гомуми нигезләмәләр.

1.1. Әлеге Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлегендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми милекне кичектергесез капиталь төзекләндерү зарурлыгы килеп чыккан очракта җирле бюдџет хисабына кире кайтару һәм (яки) кире кайтармау нигезендә өстәмә ярдәм күрсәтү очраклары исемлеге һәм тәртибе (алга таба-тәртип) Россия Федерациясе Торак кодексының 14 статьясы 9.3 пунктына туры китереп эшләнгән, һәм күпфатирлы йортларда гомуми милекне кичектергесез капиталь төзекләндерү үткәрү өчен кичектергесез чаралар кабул итүне таләп итә торган очраклар исемлеген һәм җирле бюджет хисабына кире кайтару һәм (яки) кире кайтармау нигезендә өстәмә ярдәм күрсәтү процедурасын билгели.

1.2. Әлеге карар Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлегендә урнашкан күпфатирлы йортларга җәелдерелә.

1.3. Күпфатирлы йортларда гомуми милекне кичектергесез капиталь төзекләндерү зарурлыгы килеп чыккан очракта җирле бюджет хисабына кире кайтару һәм (яки) кире кайтармау нигезендә өстәмә ярдәм күрсәтү очраклары исемлеге үз эченә түбәндәгеләрне ала:

- янгыннар һәм шартлаулар;
- биналар һәм корылмаларның кисәк җимерелүе;
- электроэнергетик системаларда аварияләр;
- тормышны тәэмин итү коммуналь системаларында, гидродинамик аварияләр;
- куркыныч геологик күренешләр;
- куркыныч метеорологик күренешләр;
- куркыныч гидрологик күренешләр;
- табигый янгыннар;
- эре террор актлары (алга таба- гадәттән тыш хәлләр).

1.4. Күпфатирлы йортларда гомуми милекне кичектергесез капиталь төзекләндерү зарурлыгы килеп чыккан очракта кире кайтару һәм (яки) кире кайтармау нигезендә өстәмә ярдәм җирле бюджет хисабына бирелә.

1.5. Өстәмә ярдәм максатчан характерда була һәм башка максатларга кулланыла алмый.

1.6. Күпфатирлы йортларда гомуми милекне кичектергесез капиталь төзекләндерү зарурлыгы килеп чыккан очракта кире кайтару һәм (яки) кире кайтармау нигезендә өстәмә ярдәм муниципаль берәмлекнең финанс мөмкинлекләре һәм җирле бюджетта туры килә торган статья расланган шарт белән, күпфатирлы йортларда гомуми милекне кичектергесез капиталь төзекләндерү чараларын тормышка ашыру максатында бирелә.

1.7. Өстәмә ярдәм җирле бюджетта каралган акчалар чикләрендә гариза тәртибендә бирелә.

1.8. Өстәмә ярдәм бирүче, бюджет акчаларын төп бүлүче булып Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге башкарма комитеты тора.(алга таба- башкарма комитет)

1.9. Россия Федерациясе Торак кодексының 191 статьясы 1 кисәгенә туры китереп, күпфатирлы йортларда гомуми милекне кичектергесез капиталь төзекләндерү зарурлыгы килеп чыккан очракта кире кайтару һәм (яки) кире кайтармау нигезендә өстәмә ярдәм Россия Федерациясе Торак кодексына туры китереп, барлыкка килгән торак милекчеләре ширкәтенә, торак, торак-төзелеш кооперативларына, идарә итүче оешмаларга, күпфатирлы йортларны капиталь төзекләндерү региональ операторына бирелә. (алга таба- оператор, ярдәм алучылар)

1.10. Җирле бюджет акчаларын бирү өчен мәҗбүри шартлар булып тора:

- Күпфатирлы йортта гомуми милекне капиталь төзекләндерү өчен күпфатирлы йортта яшәүче милекчеләр җыйган махсус хисаптагы акчаларның җитәрлек булмавы;

- Күпфатирлы йортта яшәүче милек хуҗаларының капиталь төзекләндерү өчен махсус хисапка түләнә торган кертемнәр буенча әҗәте капиталь төзекләндерү өчен хисапланган гомуми суммасыннан 5(биш) % тан артмаска тиеш.

1.11. Җирле бюджет акчалары күчерелә:

- күпфатирлы йортта гомуми милеккә капиталь төзекләндерү кертемнәре күчерелә торган махсус хисапка, региональ операторга субсидия формасында;

- капиталь төзекләндерү фондын махсус хисапларда формалаштыручы биналарның милекчеләре, тиешле күпфатирлы йорт белән идарә итүне башкаручылар булып торучы торак милекчеләре ширкәте, торак кооперативы яки идарә итүче оешмага күпфатирлы йортта капиталь төзекләндерү уздыру буенча муниципаль ярдәм күрсәтү өчен субсидия формасында.

## 2. Өстәмә ярдәм күрсәтүнең шартлары һәм тәртибе.

2.1. Күпфатирлы йортларда гомуми милекне кичектергесез капиталь төзекләндерү зарурлыгы килеп чыккан очракта кире кайтару һәм (яки) кире кайтармау нигезендә өстәмә ярдәм күрсәтү турында карар (алга таба- карар) Башкарма комитет карары белән раслана. Ярдәм күрсәтүдән баш тарту турында карар кабул ителсә, хат җибәрелә.

2.2. Карар кабул итү өчен Шәмәрдән авыл җирлеге башкарма комитеты, торак милекчеләре исеменнән гамәл кылырга вәкаләтле затларның мөрәҗәгате нигезендә, әлеге тәртипнең 1.3 пунктында күрсәтелгән очрак килеп чыкканнан соң 30 календарь көн

эчендә, башкарма комитетка капиталь төзекләндерү үткәрү зарурлыгы турында түбәндәге документларны теркәп, мәгълүмат бирә:

2.2.1. күпфатирлы йортның адресын, капиталь төзекләндерүнең билгеләнешен, гомуми суммасын, булган финанс чыганаклары хисабына капиталь төзекләндерүнең тәэмин ителешен һәм зарури өстәмә ярдәм күләмен, өстәмә ярдәмне кире кайтару һәм түләү чыганакларын, кире кайтару срокларын күрсәтеп, өстәмә ярдәм күрсәтү турында гариза;

2.2.2. оештыру документларының расланган нөсхәләре, юридик затның дәүләт теркәве узуы турында таныклыгы, юридик затларның бердәм дәүләт реестрына теркәлүе турында таныклык, урнашу урыны буенча салым органында исәптә торуы турында таныклык, банк счеты булуын раслаучы документ, банк счетының реквизитлары. Әгәр гариза бирүче, идарә белән килешү нигезендә күпфатирлы йорт белән идарә итүче зат булса, өстәмә рәвештә күпфатирлы йортта яшәүчеләрнең күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау һәм идарә итүче оешманы сайлау турында гомуми җыелышы беркетмәсеннән күчермә бирелә. Санап кителгән документлар агымдагы елда бер тапкыр бирелә. Бирелгән мәгълүматның актуальлеге турында җаваплылык гариза бирүчегә йөкләнә.

2.2.3. йортны капиталь төзекләндерү кирәклеге турында милекчеләрнең гомуми җыелышы беркетмәсе(карары) күчермәсе;

2.2.4. йортны тикшерү акты;

2.2.5. күпфатирлы йортка капиталь төзекләндерү үткәрү соравы хәл ителүче күпфатирлы йортның гомуми милкенең техник торышы турында мәгълүматлар,

2.2.6. “Техник инвентаризаөия бюросы” Республика дәүләт унитар предприятиесе, Татарстан Республикасының төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының күпфатирлы йорттагы гомуми милекнең торышы турында бәяләмәсе;

2.2.7. дәүләт сәясәтен тормышка ашыру һәм эшләп чыгару функциясен башкаручы, норматив-хокукый җайга салучы, шулай ук гражданлык оборонасы өлкәсендә контроль һәм күзәтчелек итүче, халыкны һәм территорияне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклаучы, муниципаль берәмлек территориясендәге су объектларында кешеләрнең куркынычсызлыгын һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итүче органның гадәттән тыш хәлләрне тану турында карары;

2.2.8. капиталь төзекләндерү буенча эш һәм(яки) хезмәтләр исемлеге;

2.2.9. техник заказчы тикшергән капиталь төзекләндерү буенча хезмәт күрсәтү һәм (яки) эш башкару чыгымнары сметасы;

2.2.10. яшәүчеләрнең мөрәҗәгатьләре, тикшерүче органнарның күрсәтмәләре һәм суд карарлары, махсус оешмаларның актлары, башка документлар башкарасы эшләрнең кичектергесезлеген нигезләү максатында, гариза бирүченең карары белән гаризага теркәлә.

2.3. Әлеге Тәртипнең 2.2 пункты нигезендә ярдәм алучы тәкъдим иткән мәгълүмат нигезендә Башкарма комитет аны алган көннән башлап 15 календарь көн эчендә күпфатирлы йортта гомуми милекне капиталь ремонтлау буенча хезмәтләр һәм (яки) эшләр исемлеген раслау, кичектергесез ихтыяҗ барлыкка килгән очракта, капиталь ремонт һәм

аны финанслау чыганаклары буенча хезмәтләрнең һәм (яки) эшләрнең рөхсәт ителгән кыйммәтен раслау турында норматив хокукый акт проектын эшли.

2.4. Өстәмә ярдәмне бүлү турында Карар кабул ителгәннән соң 7 (җиде) көн эчендә Башкарма комитет ярдәм алучыларга хәбәр итәргә тиеш.

2.5. Өстәмә ярдәм ярдәм алучыларга ярдәм күрсәтү турында килешү нигезендә (алга таба – килешү) бирелә.

2.6. Башкарма комитетның региональ оператор, торак милекчеләре ширкәте, торак, торак-төзелеш кооперативы белән Россия Федерациясенең торак кодексына туры китереп төзелгән идарәче оешма белән килешүе күз алдында тотарга тиеш:

- субсидия күләмен, максатларын, аны бирү шартларын һәм срокларын;

- җирле бюджеттан акча күчерү тәртибен;

- субсидияләр куллануның нәтиҗәлелеге һәм нәтиҗәлелек күрсәткече зурлыгына ирешү буенча йөкләмәне;

- субсидияләр биргәндә билгеләнгән шартлар бозылган очракларда субсидияләрне кире кайтару срокларын һәм тәртибен, субсидияләрдән файдалануның нәтиҗәлелеге һәм нәтиҗәлелек күрсәткече әһәмиятен, аларны максатсыз файдалануны, шулай ук файдаланылмаган субсидияләрне кире кайтару тәртибен;

- субсидияләр алучының Башкарма комитет һәм муниципаль финанс контроле органнары тарафыннан субсидияләр бирү шартларын, максатларын һәм тәртибе үтәлешен тикшерүне гамәлгә ашыруга ризалык бирүне;

- бирелгән субсидияләрне тулысынча, вакытында һәм нәтиҗәле үзләштергән өчен, шулай ук хисапларда бирелгән мәгълүматның дөреслеге өчен субсидия алучы җаваплылыгын.

2.7. Ярдәм күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тора:

2.7.1. әлеге Тәртипнең 1.3, 1.9, 1.10 пунктларында каралган ярдәм күрсәтү өчен нигез булмавы;

2.7.2. ярдәм алучылар әлеге Тәртипнең 2.2 пунктында китерелгән капиталь ремонт фондын формалаштыручы махсус счетларны, тиешле документларны тапшырмавы;

2.7.3. ярдәм алучы тарафыннан тәкъдим ителгән мәгълүматның дөрес булмавы.

2.8. Башкарма комитет һәм оператор арасында ярдәм бүлү турындагы килешү төзелгәннән соң, җирле бюджет акчалары Башкарма комитет тарафыннан операторның аерым банк счетына күчерелә.

2.9. Шартлар бозу, ярдәм күрсәтү, шулай ук подрядчы оешмаларны сайлап алу буенча конкурслар үткәрү нәтиҗәсендә алынган ярдәмне экономияләү очраклары

ачыкланган очракта, файдаланылмый торган акчалар җирле бюджет керемено килешү буенча күчерелә.

2.10. Капиталь ремонт фондын формалаштыручы махсус счетта ярдәм алучылар аерым банк счетларын ачалар. Шул ук вакытта күпфатирлы йортларны капиталь ремонтлауга муниципаль ярдәм чараларын күчерү өчен һәр күпфатирлы йортка бер банк счеты ачыла һәм Башкарма комитетка җибәрелә:

1) мондый счетларны ачу турында аларның реквизитлары күрсәтелгән хәбәрнамә;

2) капиталь ремонт үткәрү турында килешү төзиячәк организацияне билгели торган капиталь ремонт үткәрү турында Россия Федерациясе Торак кодексының 189 статьясы таләпләре нигезендә кабул ителгән карар;

3) Россия Федерациясе Торак кодексының 189 статьясы таләпләренә туры китереп, әлеге йорт өчен билгеләнгән эшләр исемлеген исәпкә алып, әлеге йортны капиталь төзекләндерү чыгымнары сметасын, капиталь төзекләндерү буенча хезмәтләрнең һәм (яки) эшләрнең чик бәясен исәпкә алып, раслау.

2.11. Әлеге Тәртипнең 2.9 пунктында күрсәтелгән документлар кергән көннән соң 5 (биш) эш көне эчендә Башкарма комитет ярдәм алучы белән килешү төзи һәм тиешле күпфатирлы йортка капиталь ремонт үткәрү өчен каралган акчаларны күчерә.

2.12. Ярдәм күрсәтү шартларын бозу фактлары ачыкланган очракта, шулай ук подрядчы оешмаларны сайлап алу буенча конкурслар үткәрү нәтиҗәсендә алынган ярдәмне экономияләү килеп туган очракта, үзләштерелмәгән акчалар җирле бюджет керемено күчерелергә тиеш.

2.13. Ярдәм алучы күпфатирлы йортның гомуми милеген капиталь ремонтлау буенча хезмәтләр һәм (яки) эшләр өчен Башкарма комитет белән килештерелгән күпфатирлы йортның уртак милеген кабул итү һәм (яки) капиталь төзекләндерү буенча эшләр кабул итү актлары һәм (яки) эшләр нигезендә, күпфатирлы йортта биналарның милекчеләр исеменнән эш итәргә вәкаләтле затлар тарафыннан кул куелган түләү башкара.

Югары технологияле чит ил җиһазларын, чимал һәм комплектлау әйберләрен сатып алганда (җибәргәндә) Россия Федерациясенең валюта законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган операцияләрдән тыш, чит ил валютасы акчаларын алучылар тарафыннан сатып алу тыела.

2.14. Башкарма комитет тарафыннан күпфатирлы йортны капиталь төзекләндерү буенча хезмәтләрне һәм (яки) эшләрне кабул итү актын килештерүдән баш тарту расланган сметада каралмаган эшләргә түләү өчен, шулай ук әлеге йортны капиталь төзекләндерүгә элек расланган сметадан артып киткән очракта рөхсәт ителә.

2.15. Капиталь төзекләндерү буенча башкарылган эшләрне һәм (яки) күрсәтелгән хезмәтләрне кабул итү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Күпфатирлы йортта гомуми милекне капиталь төзекләндерү буенча башкарылган эшләрне һәм (яки) күрсәтелгән хезмәтләрне кабул итү тәртибен билгеләү турында " 2016 елның 9 июнендәге 378 номерлы карары белән билгеләнгән тәртип нигезендә башкарыла.

**3. Күпфатирлы йортта гомуми милекне капиталь төзекләндерү буенча хезмәтләр һәм (яки) эшләр исемлеге**

Шәмәрдән авыл җирлеге территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь төзекләндерү буенча хезмәтләр һәм (яки) эшләр исемлеге, капиталь төзекләндерү фонды акчалары хисабына финанслана торган хезмәтләр исемлеге, шулай ук капиталь төзекләндерүгә дәүләт ярдәме чаралары хисабына, шулай ук кире кайтаруга һәм (яки) кире кайтарылмауга җирле бюджет акчалары хисабына кичектергесез өстәмә ярдәм күрсәтү үз эченә ала:

1) йорт эчендәге электр, җылылык, газ, су белән тәэмин итү, ташландык суларны агызу инженерлык системаларын ремонтлау;

2) түбәне ремонтлау;

3) түбәне төзекләндерү кирәклеге тиешле тикшерү нәтиҗәләре буенча әзерләнгән махсуслаштырылган оешма бәяләмәсе белән билгеләнгән очракта, җиллләтелми торган түбәне җиллләтелә торган түбәгә үзгәртеп корылырга;

4) күпфатирлы йортта гомуми милеккә караган подвал биналарын төзекләндерү;

5) фасадны төзекләндерү;

6) күпфатирлы йортны Энергетика тикшерүе нәтиҗәләре буенча әзерләнгән махсуслаштырылган оешма бәяләмәсе белән әлеге эшләрне үткәрү зарурлыгы билгеләнгән очракта фасадны җылыту;

7) күпфатирлы йортның фундаментын төзекләндерү;

8) Россия Федерациясе законнары белән аны эшләү таләп ителгән очракта проект документларын эшләү;

9) Россия Федерациясе законнары белән мондый экспертизалар үткәрү таләп ителсә, архитектура һәйкәлләре тарафыннан рәсми рәвештә танылган күпфатирлы йортларга карата проектка, тарихи-мәдәни экспертиза үткәрү;

10) төзелеш контролен гамәлгә ашыру.

**4. Ярдәм күрсәтү тәртибен, шартларын һәм максатларын үтәүне тикшереп торуны һәм аларны бозган өчен җаваплылыкны гамәлгә ашыру турында таләпләр**

4.1. Ярдәм түбәндәге очракларда җирле бюджетка кире кайтарылырга тиеш:

4.1.1. аерым банк счетында аккумуляцияләнгән акчаларны (ремонт эшләрен һәм подрядчы оешмалар белән исәп-хисапларны тулы күләмдә тәмамлау шарты белән) җыю яисә тулысынча үзләштерелмәгәндә;

4.1.2. Башкарма комитет һәм муниципаль финанс органнары тарафыннан тикшерү нәтиҗәләре буенча ярдәм алучының бирелгән акчаларны максатчан файдаланмавы ачыкланса;

4.1.3. алучы тарафыннан килешүдә каралган йөкләмәләрне, шул исәптән халыкка сыйфатлы хезмәт күрсәтү үтәлмәгән һәм (яки) тиешенчә башкарылмаганда;

4.1.4. акча һәм (яки) чыгымнарны раслаучы документлар алу өчен дөрес булмаган мәгълүматлар бирү факты ачыкланса;

4.1.5.  ярдәм алучы үзгәрсә яки бөлгенлеккә төшсә;

4.1.6. Башкарма комитет һәм муниципаль финанс органнары үткәргән тикшерүләр буенча ярдәм алучы тарафыннан билгеләнгән шартларның бозылуы ачыкланса;

4.1.7. гамәлдәге законнарда каралган башка очракларда.

4.2. Ярдәм күрсәтү турында килешүдә каралган шартларны максатчан файдаланмау яисә үтәмәү факты тикшерү акты белән билгеләнә, анда ачыкланган бозулар һәм аларны бетерү сроклары күрсәтелә.

4.3. Акчаны кире кайтару тикшерү актын алганнан соң 10 (ун) эш көне эчендә ярдәм алучы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4.4. Хисап финанс елында файдаланылмый калган ярдәмне алучы тарафыннан килешү нигезендә каралган очракларда кире кайтару билгеләнгән хисаптан соң 10 (ун) эш көне эчендә ярдәм алучы тарафыннан агымдагы финанс елында гамәлгә ашырыла.

4.5. Ярдәм күрсәтүдән баш тарткан ярдәм алучы, акчаны ирекле рәвештә кире кайтарудан баш тартканда, түләтүләр Россия Федерациясе законнары нигезендә һәм тәртиптә башкарыла.

4.6. Аны алучылар тарафыннан ярдәм күрсәтү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүне мәҗбүри тикшерүләр Башкарма комитет һәм муниципаль финанс контроле органнары тарафыннан муниципаль хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

4.7. Ярдәм күрсәтү һәм куллану процессында барлыкка килә торган каршылыклар һәм бәхәсләр гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә хәл ителә.